Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

12+

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№26 (77)

5 сентябрь 2013 ел

## *Хөрмәтле беренче курс студентлары!*

Сезне чын күңелдән Казан университетына укырга керүегез белән тәбрик итәм. Сез Россиядә иң борынгы уку йортларының берсе булган университетның бусагасын атлап кердегез. Ике гасырдан артык тарихы булган уку йорты 110 меңләп кешене дипломлы белгеч итте, аларның күбесе төрле өлкәдә: фән, мәдәният, дәүләт идарәсе, хуҗалык-оештыру эшләрендә зур үрләр яулады. Федераль уку йорты дәрәҗәсен алгач, университет студентларны заманча белем бирү мөмкинлеге белән беррәттән, реаль икътисад, IT-тармак, банк эшчәнлеге, идарә итү өлкәсендә өстәмә күнекмәләр белән дә тәэмин итә. Безнең университет структуралары ватаныбыз һәм чит ил партнерлары белән тыгыз бәйләнештә булган эре фәнни-белем бирү холдингына әйләнде. Хезмәттәшлек, академик өлкә белән беррәттән, уртак кафедралар, лабораторияләр, җитештерү үзәкләре, кече инновацион предприятияләр кысаларында, шул ук вакытта икътисадның реаль секторында да алып барыла. Яңа фәнни-белем бирү структурасы барлыкка килде (21 институт һәм 2 факультет), яңа җиһазлар базасы белән тәэмин ителгән 130дан артык лаборатория ачылды һәм модернизацияләнде.

Үзегезне тизрәк безнең зур һәм бердәм коллективның тулы хокуклы әгъзасы итеп тойсагыз иде. Моңа безнең өчен мөһим булган тарихи вакыйгага – Казан университетының 210 еллыгына әзерләнү атмосферасы да (2014 ел Казан университетының 210 еллыгы дип игълан ителде), һичшиксез, булышлык итәчәк. Әлеге истәлекле вакыйгага әзерләнү процессы сезгә университетыбызның данлыклы тарихына якынаерга һәм хәзерге тормышын тирәнрәк аңларга ярдәм итәчәк. Бу тормыш бик төрле, бай эчтәлекле һәм бүген аның төп юнәлеше дә бар: дөньяның әйдәп бара торган фәнни-белем бирү үзәкләре төркеменә керү. Без бу максатка көннән-көн якынаябыз! Күптән түгел Россиянең әйдәп бара торган вузлары арасында әлеге амбициоз мәсьәләне хәл итү өчен дәүләт субсидиясен алу хокукына бәйле конкурс оештырылган иде. Безнең университет бу ярышта җиңеп чыкты! Шуңа күрә безгә югары квалификацияле белгечләр була алырдай студентлар кирәк. Быел без бик лаеклы буынны кабул иттек. БДИның уртача баллы узган елдагыдан күпкә югары – 80нән дә күбрәк, беренче курслар исә Россия Федерациясенең дүрттән өч диярлек субъект вәкилләрен тәшкил итә.

Сез университетка Универсиада 2013 тәмамлангач та килдегез. Сезгә кадәрге буын дөньякүләм студентлар спорт форумын Казанда үткәрүгә һәм әзерләүгә бик зур өлеш керттеләр. Универсиадада катнашкан Татарстанның һәр өч спортчысы – безнең университет вәкилләре. Алар 11 медаль яуладылар, шуларның 4се алтын. Алай гына да түгел, һәр бишенче спорт волонтеры - безнең студент иде, ә бу 20 меңнән артык кеше дигән сүз. Сезгә Универсиададан калган мирасны, университетыбызга күчкән Универсиада авылын үзләштерергә туры киләчәк. Бу безгә читтән килгән студентларны 100% тулай торак белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирә. Сезне спорт төрләре буенча 30дан артык секцияле яңа «Мәскәү» һәм «Бустан» спорт комлекслары көтә.

Куйган максатларыгызга омтылыгыз һәм, һичшиксез, моңа ирешәчәксез. Мин, үз чиратымда, сезгә укуда, спортта, иҗатның төрле өлкәләрендә уңышлар һәм, иң мөһиме, тормышта лаеклы урын табуыгызны телим!

*Илшат Гафуров,*
*КФУ ректоры*


Диана Поварова фотолары

# Белем бәхетле итә!

**Динара МИННЕКАЕВА**, хәбәрче

Казан федераль университеты Белем көнен бик зурлап Спорт Сараенда уздырды. Тантаналы чарада биш мең беренче курс студенты катнашты.

Уку йорты җитәкчелеге, зур кунаклар, чыгарылыш студентлары беренче курслар белән бергә бәйрәм итте. КФУ ректоры Илшат Гафуров: «Сезгә Россиянең иң алдынгы, шул ук вакытта тарихи уку йорты – Казан федераль университеты студентлары булу өчен зур юл үтәргә туры килде. Сезнең бик матур бүгенге көнегез бар, киләчәгегез дә шундый ук якты булыр дип ышанам. Ә аны нәкъ менә сез төзисез. Сез монда якын дусларыгызны, гомер юлдашларыгызны да табарсыз, шул ук вакытта барлык уйхыялларыгызны да тормышка ашыра алырсыз. Шуңа күрә һәрвакыт алга омтылыгыз!» – диде. Чара матур концерт номерлары, төрле видеороликлар белән үрелеп барды. Беренче курслар өчен бик матур җырлар, күңелле биюләр башкарылды, изге теләкләр яңгырады.

Беренче сентябрь дип әйткәндә, ни өчендер көз башы да түгел, бакчадагы пешкән җиләк-җимеш тә түгел, ә нәкъ менә мәктәпкә барган беренче уку көне күз алдына килә. Хәзер көз аеның беренче көнен Белем көне дип олылап йөртәләр. Чынлап та, нәкъ менә мәктәп бусагасыннан беренче адым атлап кергән нәниләр өчен әлеге бәйрәм белем дәрьясына алып кереп китә торган беренче инеш булып тора. Әлеге Белем диңгезендә кемнең ничек йөзүе күп әйбергә бәйле. Диңгез океаннарга кушылсын өчен, мәктәп, укытучылар, андагы мохит зур роль уйный. Уку йортыбызга кергән кичәге мәктәп укучылары бүген инде студент булды! Дуслар, сез игә-чигә күренми торган Белем океанында йөзә башлыйсыз. Юлыгызда зур-зур дулкыннар да, агым уңаена тыныч кына йөзүләр дә булыр. Борчылмагыз, сезгә юл күрсәтүчеләр авырлыкларны тиз һәм җиңел генә үтеп китәргә ярдәм итәр.

Уку йортыбыз турында туган беренче хисләр сезне студент еллары дәвамында озатып барыр, дип ышанабыз. Биредә тудырылган һәр мөмкинлектән файдаланырга өйрәнегез. Ә уку йорты ил күләмендә кайнарга гына түгел, хәтта дөньяга чыгарга ярдәм итәчәк. Онытмагыз: белемле кеше беркайда да югалмый!

● Безнең канат

# КФУ «укучылары»!

**Динә МӨХТӘСИПОВА**, хәбәрче

Яңа уку елы университет өчен генә түгел, ә аның базасында эшли торган лицейлар өчен дә зур яңалыклар алып килде.

Н.И.Лобачевский исемендәге лицей тарихында Белем көне аеруча истәлекле вакыйга булып калачак. Ул быел укучыларын Казан федераль университетының яңа зур бер структур бүлеге буларак каршы алды. Быел лицейга 79 яңа укучы кабул ителде, ә барлыгы алар – 509 укучы.

**Ахыры 2нче биттә.**


Юлия Карпова фотосы

## • Вакыйгалар эзеннән

2013 елда Россиянең әйдәп бара торган **ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЛАРЫНА** ярдәм максатыннан федераль бюджеттан **8,7 МЛРД. СУМ** бүлеп бирелде. Казан федераль университетына, башка 13 дәүләт югары уку йортлары белән беррәттән, бу суммадан 592,4 миллион сум өлеш чыгарылды. Әлеге субсидиянең 50% фәнни һәм белем бирүне интернациональләштерүне арттыру максатында тотылыр дип планлаштырыла. Федераль субсидия КФУның төп үсеш юнәлешләре буенча белгечләрне әзерләү һәм фәнни тикшеренүләрне активлаштыруга файдаланылачак.

• • • •

Ректор **И.ГАФУРОВ** һәм **КФУ КОЛЛЕКТИВЫ** исеменә А.Вавилова фондыннан ТРның беренче балалар хосписын төзүгә матди ярдәм күрсәткән өчен **РӘХМӘТ ХАТЫ** килде.

• • • •

**30 АВГУСТТА КФУ**га РФ Мәгариф һәм фән министры урынбасары **АЛЕКСАНДР ПОВАЛКО** килде. Көннең беренче яртысында ул уку йортының материаль-техник базасы белән танышты, ТР Мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов һәм КФУ ректоры Илшат Гафуров белән бергәләп, Физика институты, А.М.Бутлеров исемендәге Химия институты, Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты, Фундаменталь медицина һәм биология институты лабораторияләрен карап чыкты. Көннең икенче яртысында Александр Повалко КФУ ректораты утырышында катнашты.

• • • •

**4 СЕНТЯБРЬ КӨННЕ** Лобачевский исемендәге фәнни китапханәдә яшь галим һәм белгечләрнең **«ЯШЕЛ ИКЪТИСАД: ЭКОЛАДОГАДАН АСТАНА ФОРУМЫНА КАДӘР»** исемле төбәкара **КИҢӘШМӘЛӘРЕ** узды. Җыелышта Евразия (Мәскәү, Казан, Уфа, Мюнхен, Киев, Петрозаводск, Сортаваль, Екатеринбург) союзы әгъзалары – яшь галимнәр һәм белгечләр яшел икътисадка һәм 2014 елның маенда Астанада булачак Икътисади форум мәсьәләләренә кагылышлы конференцияләр эстафетасын уздыру турында фикер алыштылар.

• • • •

Бүген **«НЕЙРОННАН БАШ МИЕНӘ КАДӘР»** халыкара фәнни конференция үз эшчәнлеген башлап җибәрде. Ул ике көн дәвам итәчәк. Чара университетыбызның Фундаменталь медицина һәм биология институтында нейробиология фәнни-тикшеренү лабораториясенең тантаналы ачылышы уңаеннан оештырыла. Конференция кысаларында ватаныбыз һәм чит ил галимнәре чыгыш ясыйлар. Нейрофизиологиянең Казандагы вәкилләре белән беррәттән, нейрофәне өлкәсенең мөһим тикшеренү эшләре хакында лекцияләрендә К.Анохин (Курчатов институты, Мәскәү), П.Балабан (Россия Фәннәр академияснең Югары нерв эшчәнлеге һәм нейрофизиология институты, Мәскәү), А.Репреза (Урта диңгез нейробиология институты, Марсель, Франция), Р.Гиниатуллин (Куопио университеты, Куопио, Финляндия) сөйләячәкләр.

• • • •

**3 СЕНТЯБРЬ** көнне **КФУ**ның **IT-ЛИЦЕЕНА** телевизион тапшырулар алып баручы, җәмәгать эшлеклесе **ТИНА КАНДЕЛАКИ ВИЗИТ** ясады. Ул лицейга ТР Премьер-министры урынбасары – ТР Министрлар Кабинеты Аппараты җитәкчесе Шамил Гафаров, ТР Премьер-министры урынбасары вазифасын башкаручы – ТР Мәгариф һәм фән министры Энгел Фәттахов, КФУның вузга кадәрле, гомуми һәм педагогик белем бирү департаменты директоры Людмила Ногмановалар белән бергә килде. Тина Канделаки лицейчылар белән аралашты, алар белән истәлек фотоларына төште. Кунак инглиз телендә үтә торган биология һәм физика дәресләрендә, авиа модельләштерү лабораториясендә һәм Берләшкән Милләтләр Оешмасының халыкара модельләре штабында булды.

• • • •

Бүген 18.00дә УНИКС концертлар залында **КЕЧЕ УНИВЕРСИТЕТНЫҢ** яңа 2013-2014 уку елына багышланган **ҖЫЕЛЫШ** була. Анда укырга кабул итү мәсьәләләре хәл ителәчәк.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*

# КФУ «укучылары»!

**Башы 1нче биттә.**

Барлык укытучылар коллективын, укучыларны, ата-аналарны бәйрәм белән котлау өчен, лицейга ректор **И.Гафуров** җитәкчелегендә уку йорты галимнәре дә килде. «Бу бик тә үзенчәлекле көн, шуңа күрә без сезне зур делегация белән котларга килдек. Сез илле меңнән артык студенты булган федераль уку йорты базасында белем алачаксыз. Безнең алда зур бурычлар тора: корпоратив рух тәрбияләү, институтлар, кафедралар белән үзара мөнәсәбәт урнаштырудан башлап, уртак мәдәни программаларны тормышка ашырачакбыз. Университеттагы барлык мөмкинлекләрдән сез дә файдалана алачаксыз. Сезгә зур уңышлар телим! Биредә укуыгызга беркайчан да үкенмәссез, дип уйлыйм», – диде. Тантаналы чара яңа уку елы хөрмәтенә флаг күтәрү белән тәмамланды.

Бер ел элек ачылган IT- лицейда да Белем бәйрәме бик күңелле узды. Котлаулардан соң, укучылар үзләренең талантларын да күрсәтте. Ата-аналар белән очрашуда ректор алар өчен яхшы яңалыклар да җиткерде. «Сез балаларыгыз белән даими күрешеп, аралашып торсын өчен, Универсиада авылында берничә кунакханә номерлары ачарга планлаштырабыз. Ул Казандагы иң арзан кунакханә булачак. Балаларыгыз белән рәхәтләнеп аралашып, төн кунып ял итә алырсыз», – диде. Лицей үзендә зур кунаклар кабул итүен икенче көнне дә дәвам итте. 3 сентябрь көнне бирегә Россия Хөкүмәте рәисе **Игорь Шувалов** килде. Аны ТР Президенты **Рөстәм Миңнеханов**, премьер-министры вазифасын башкаручы, мәгариф һәм фән министры **Энгель Фәттахов**, ректор Илшат Гафуров озатып йөрде. Мәскәү кунагы башта лицейда тудырылган мөмкинлекләр, спорт залы белән танышты. Аннан соң Educare Сингапур компаниясе тормышка ашыра торган мәгарифне модернизацияләү программасы тәкъдим ителде. IT-лицейда нәкъ шул программа буенча укыталар. Әлеге программа кысаларында Татарстанда инде мәгълүмати-методик үзәкләр оештырылган һәм аларда эшләү өчен, республикадан 388 белгеч Сингапурда белемен арттырган. Шул белгечләр Татарстанның 10800 укытучысын заманча белем бирү серләренә төшендерәчәк.

Шулай ук И.Шувалов игътибарына инглиз теле укытучыларының белемен күтәрү программасы да тәкъдир ителде. Ул программа EF School компаниясе белән тормышка ашырыла. EF School шулай ук татар телен онлайн укыту программасын да ачып җибәрде. «Татарстанда яшәүче һәр кеше, нинди милләттән булуына карамастан, татарча белергә тиеш», – диде беренче вице-премьер.



Марсель Бадыкшин фотосы

## • Уртак җиңү

# Эшне яратып эшләсәң!

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

Яңа уку елын шатлыклы хәбәрләр белән башлап җибәрү икеләтә сөендерә. Шушы көннәрдә Россия хәрби-тарихи фәннәр академиясе берничә тарихчы галимне Ватан тарихы фәненә зур өлеш керткәннәре, студентлар һәм яшьләр арасында актив хәрби-патриотик эшчәнлек алып барганнары өчен медальләр белән бүләкләде. Алар арасында КФУ галимнәре дә бар.

Шушы көннәрдә «ТР хәтеркитабы»ның төп редакциясендә РФ хәрби-тарихи фәннәр академиясенең Татарстан төбәкара бүлегенең (РФ ХТФА ТТБ) чираттагы утырышы вакытында академик, әгъза-корреспондент дипломнары һәм алтын, көмеш медальләр тапшыру тантанасы булды. Чараны «ТР хәтер китабы»ның баш мөхәррире, РФ ХТФА ТТБның җитәкчесе, Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты профессоры А.А.Иванов алып барды. Танылган тарихчы галимнәр һәм офицерлар диплом-медальләрне Советлар Союзы Геройлары А.Сабиров, Б.Кузнецов, Социалистик хезмәт Герое И.Мостюков кулыннан алу бәхетенә иреште.



Алтын медальгә ия булган «бәхетлеләр» исемлегендә безнең университет галимнәре дә бар: КФУның Ветераннар советы рәисе, доцент, РФ ХТФА ТТБның әгъза-корреспонденты В.Ф.Телишев; Халыкара мөнәсәбәтләр институтының тарих бүлеге профессоры, Әфганстан сугышы ветераны, РФ ХТФА ТТБ академигы А.А.Борһанов; КФУ профессоры, РФ ХТФА ТТБ академигы Р.В.Шәйдуллин. Тарих фәннәре кандидаты, ТР Президент аппараты бүлеге мөдире, РФ ХТФА ТТБның әгъза-корреспонденты Р.Б.Гайнетдиновның эшчәнлеге дә алтын медальгә лаек дип табылды.

Яшьләр арасында актив эшчәнлек алып барганы, Татарстанның Бөек Ватан сугышы еллары тарихы буенча докторлык диссертациясе һәм монография әзерләгәне өчен, ТР Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани ис. Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре, РФ ХТФА ТТБның әгъза-корреспонденты А.Ш.Кәбирова көмеш медаль белән бүләкләнде.

Университетыбыз өчен тагын бер яхшы яңалык: КФУ доценты В.Ф.Телишев РФ ХТФА ТТБ академигы статусын алды. Эшләгәнне вакытында күреп, аны бәяләп торганда, эшләү теләге дә арта, үзеңдә тагын да күбрәк көч табасың! Галимнәребез өчен бу уңышлар чик булып калмыйча, тагын да зуррак үрләр яулар өчен бер этәргеч булачак!

*✦ РФ хәрби-тарихи фәннәр академиясенең Татарстан төбәкара бүлеге – тарихчы-галимнәрне, Советлар Союзы һәм Социалистик хезмәт Геройларын, сугыш, хезмәт һәм хәрби көчләр ветераннарын офицерларны, Әфганстан сугышы ветераннарын үз тирәсенә туплап, аларны берләштереп тора торган махсус бер звено. Бүлек әгъзалары Бөек Ватан сугышы кырларындагы һәм тылдагы татарлар, һәм Татарстанның җиңү көнен якынайтудагы роле, якташларның хәрби үткәннәре турында материал җыю, аны анализлау буенча эшчәнлек алып бара, хәрби тематикага багышланган фәнни-гамәли конференцияләр һәм семинарлар оештыра, яшь көрәшчеләр, студентлар арасында төбәкне өйрәнү, хәрби-патриотик һәм интернациональ эшчәнлекне җитәкли, фәнни җыентыклар һәм монографияләр чыгара.*

## • Белми калма!

Тел институты инглиз теле кафедрасының укыту үзәге **«Һөнәри коммуникация өлкәсендә тәрҗемәче» программасына 2013/2014 уку елына кабул итә башлый**. Укырга керергә теләүчеләр өчен 5-6 сентябрь көнне 19:00 сәгатьтә икенче корпусның 414 аудиториясендә **тест биремнәрен үтәү булачак**. 3 ел укыганнан соң (1500 сәгать), программаны үзләштерүчеләр дәүләт дипломы (югары белемгә өстәмә) алачак. **Укулар 15 сентябрьдәр башлана.** Түләү: **35000 сум** (семестрлап та түләргә ярый) Тулырак мәгълүматны 231-51-29 телефонына шалтыратып та белергә мөмкин.

• Мөнбәр

# Дөньяга таныта татар моңы…

**Илмира КАМАЕВА,** татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге

Студентлар өчен җәй ял чоры булса да, араларында әлеге ялларын кызыклы һәм файдалы үткәрү белән бергә гөрләтеп, иҗатта кайнаучылары да житәрлек. Бүгенге әңгәмәдәшләребез Идарә һәм территориаль үсеш институты студентлары Алия Фәйзуллина һәм Гөлчәчәк Мөхәммәтҗанова да әнә шундыйлардан. Алар август аенда Украинаның Евпатория шәһәрендә узган Х Халыкара Кырым татарлары һәм төрки мәдәниятләрнең «Гөзләв капусы» фестивалендә Татарстан данын яклап чыгыш ясадылар һәм әлеге конкурсның лауреатлары исеменә лаек булдылар.

**– Кызлар, сезне, беренче чиратта, әлеге җиңүегез белән тәбриклисе килә. Бәйге турында тулырак сөйләп үтегез әле.**

***Алия:*** Әлеге фестиваль кысаларында вокал сәнгатен, Кырым татарлары һәм төрки халыкларның мәдәниятен үстерү һәм нығыту максатыннан, вокал буенча «Алтын сес» конкурсы уздырыла. Бу бәйгедә төрле илләрдән килгән конкурсантлар катнашты. Безнең дуэт жюри тарафыннан югары бәяләнде һәм без икенче дәрәҗәдәге лауреат исемен яулагa ирештек.

**– Фестивальнең иң истә калган мизгелләре белән дә уртаклашсагыз иде?**

***Гөлчәчәк:*** Күңел ачу программасы бик үзенчәлекле һәм кызыклы булды. Дүрт көн эчендә без фестивальнең ачылу тантанасында чыгыш ясарга, Балаклаведа булырга, Кырым ярымутравының истәлекле урыннары белән танышырга өлгердек. Фестивальнең соңгы көне исә тагын да истә калырлык булды: конкурста катнашучы илләрнең театральләшкән тамашасы, җиңүчеләрне бүләкләү һәм салют…



**– Бәйгедә нинди җырлар белән чыгыш ясадыгыз?**

***Гөлчәчәк:*** Ачылу тантанасында Алия Фәйзуллинаның «Яратма» җыры белән чыгыш ясасак, фестивальнең ябылу концертында исә, композитор Резеда Ахиярованың «Зәңгәр томан» җырын башкардык. Әлеге җыр сәхнә тирәсенә барлык ватандашларны җыйды. Шундый күпсанлы тамашачы алдында чыгыш ясауның тәэсирләрен сөйләп кенә бетереп булмый.

**– Туган илдән ерактa ватандашларыбыз белән аралашу ничек булды соң?**

***Алия:*** Кырым татарларының мәдәнияте безнеке белән бик якын, шунлыктан алар белән аралашу кыенлыклар тудырмады. Бирелә без күп дуслар, фикердәшләр таптык. Киләчәктә дә алар белән аралашуны дәвам итәрбез дип уйлыйбыз.

***Гөлчәчәк:*** Даими дусларыбыз – Казанның һәм Евпаториянең әйдәп баручы архитекторлары – Альберт һәм Татьяна Савченколарның ярдәмен тоеп тору үзе бер рәхәт булды. Алар безнең чыгышларны караргa йөрделәр, Кырым ярымутравының иң матур җирләрен дә күрсәттеләр.

**– Кызлар, сез бөтенләй башка өлкә буенча белем аласыз. Шул ук вакытта җырларга, төрле бәйгеләрдә җиңү яуларга да өлгерәсез. Музыка белән кайчаннан бирле шөгыльләнәсез?**

***Алия:*** Минем гаиләм бик музыкаль. Әтием баянда уйный, әнием җырлый, абыем гитарада уйный. Әбием белән бабам да концертлар куеп йөргәннәр. Шулай булса да, гаиләмдә мин музыкаль белем алган беренче кеше. 2007 елда музыка мәктәбен кызыл дипломга тәмамладым. Музыкага гашыйк булсам да, башка һөнәр үзләштерәсем килде. Ул – дәүләти һәм муниципаль оешмалар хезмәткәре. Шул һөнәрне мәдәният белән дә бәйләп булыр дип уйлыйм. Планнар күп, барысына да тырышлык кирәк.

*Кызлар әлеге зур масштаблы бәйгедә катнашу мөмкинлеге биргән фестивальнең оештыру комитетына, житәкчеләре Филология һәм сәнгать институтының сынлы сәнгать һәм дизайн кафедрасы доценты Мәдинә Мәхмут кызы Мәхмутовага һәм, әлбәттә, яраткан университетыбызга зур рәхмәтләрен белдерәләр.*

*Без дә, үз чиратыбызда, яшь йолдызларга яңа үрләр, зурдан-зур иҗади уңышлар телибез!*

• Белем баскычлары



# Табигать сагында – «Биосфера»

**Рөстәм ФӘРХУЛЛИН,** геогр.һәм экологик белем бирү теор.һәм метод.каф. ассистеты

Яшьләрдә табигатькә карата мәхәббәт тәрбияләү, экология-география өлкәсендәге белемнәрен арттыру максатында, «Костер» сәламәтләндерү лагере базасында һәр җәй саен сәләтле балалар өчен «Биосфера» лагерь-мәктәбе эшләп килә.

Туган ягыбызның матурлыгын, байлыгын саклап калып, аны киләчәк буыннарга тапшыру – изге бурычыбыз. «Биосфера» лагерь-мәктәбе безгә шул бурычны үтәргә ярдәм итә. Быел да ул экология, биология, география белән кызыксынучы укучыларны үзенә җыйды. Республика экология-биология методика үзәге тарафыннан оештырыла торган әлеге лагерь быел 22 июльдән 8 августка кадәр эшләде. Смена барышында укучылар гомуми экология, хайваннар, үсемлекләр экологиясе, гидробиология, картография, география, геология юнәлешләре буенча өстәмә белем тупладылар. Аннан тыш, алар туфракны, урманны өйрәнү өлкәсеннән дә файдалы мәгълүмат алды. Тупланган белемне балалар фәнни эшләр язып, аларны конференциядә яклап ныгытты.

Табигать фәннәре серләренә укучыларны КФУның Экология һәм география институты укытучылары Р.И.Гайсин, С.К.Гобәева, О.Ю.Деревенская, Р.Ш.Фәрхуллин төшендерде.

Лагерь эшләгән чорда яшь эколог, географ һәм урманны өйрәнүчеләр слеты узды, Татарстанның табигатьне өйрәнүче яшь тикшеренүчеләре арасында конкурс үткәрелде, алдынгылар билгеләнде. Слет нәтиҗәләре буенча абсолют җиңүче исеменә Арча районыннан Илназ Шәяхмәтов лаек булды. Җиңүчеләргә ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Экология һәм география институтыннан дипломнар тапшырды.

• Сәяхәттән кайткач

# Нәтиҗәле эшләр!

**Дания ФАТЫЙХОВА,** хәбәрче

Җәйнең соңгы көннәрендә Азнакай төбәген өйрәнү музеенда тарих һәм археология проблемасына багышланган фәнни-гамәли конференция булды.

Чара шактый нык кызыксыну уяткан: биредә танылган тарихчылар, география һәм тарих укытучылары, укучылар, музей хезмәткәрләре, җирле төбәкне өйрәнүчеләр, Казан, Мәскәү, Бөгелмә, Әлмәт, Азнакай районы массакүләм мәгълүмат чаралары әһелләре дә катнашты.

Фәнни конференция үзенең бай мәгълүматы һәм кызыклы ачышлары белән истә калды. Аны уздыру вакыты КФУ профессоры А.А.Борһанов житәкчелегендә КФУ һәм ТР Фәннәр академиясе тарихчы-археологларының Азнакай районында тикшерү эшләре алып барулары чорына туры килде. Казан галимнәре утырыш залында 2012-2013 елларда Азнакай һәм Ютазы районнарының Ык елгасы буендагы борынгы һәм урта гасыр һәйкәлләрен барлау вакытында табылган яңа археологик табышлар, ТР галимнәре һәм җирле төбәкне өйрәнүчеләр бастырган Көньяк-Көнчыгыш Татарстан археологиясе һәм тарихына багышланган китаплар һәм брошюралар күргәзмәсен оештырдылар, төбәкнең тарихи объектларын һәм табигатен өйрәнүгә багышланган презентация күрсәттеләр.

Азнакай районы башкарма комитеты житәкчесе Айдар Шәмсетдинов археологлар хезмәтенең никадәр мөһим, авыр, вак эш икәнен ассызыклады һәм үзенең дә студент вакытында әлеге фән белән кызыксынганын сөйләп узды. Алга таба ул А.Борһанов житәкчелегендәге экспедиция нәтиҗәләренең кыйммәте һәм мөһимлеге (алга таба тупланган материалны китап итеп чыгарырга ниятлиләр – авт.) турында әйткәннән соң, сүзне галимнең үзенә тапшырды. Профессор, үз чиратында, Чалпы һәм Урсай авыллары башлыкларына, мәктәп директорларына экспедициягә булышлык күрсәткәннәре өчен рәхмәт житкерде.

Иң сөендергән мизгелләрнең берсе – кешеләрнең битараф булмаулары! Азнакай халкы, районнарына археологлар килгәч, актив рәвештә материал җыярга ярдәм иткән, үзләренең табышларын, йөрәккә якын булган гаилә ядкарьләре – иске китаплар һәм төрле әйберләр алып килгәннәр. Китаплар турында әйткәндә, Түбән Стәрле авылында яшәүче 69 яшьлек педагогик хезмәт ветераны Римма Гәрәеваның иске татар телендә язылган борынгы укыту ярдәмлеген (XIX гасыр ахыры) хәзерге татар теленә күчерүе һәм аны үз пенсия акчасына бастырып чыгаруы икеләтә соклану хисе уята.





А.Шәмсетдинов һәм А.Борһанов тарихи-төбәкара эшләрдә актив катнашкан укытучы, укучы, журналист һәм музей хезмәткәрләренә Мактау грамоталары тапшырдылар.

Конференциядә катнашучы һәркем үз фикерен белдерә, әңгәмәләрдә катнаша, галимнәргә сорауларын бирә алды, үзләренең тәҗрибәләре белән дә уртаклашты. Азнакай шәһәренең 2нче нормерлы гомуми мәктәп укытучысы, «Буревестник» эко-клубы житәкчесе А.Байковның районда туристлар маршрутын булдыру идеясе һәм тәкъдимнәре аеруча кызыксыну уятты.

Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк, дип юкка гына әйтмиләр шул. Ә безнең уку йорты үткән белән киләчәк арасында ныклы күпер салу өчен зур көч куя. Университет дәрәҗәсендә генә түгел, ә республика, Россия күләмендә!

● Җәйге ял

# Авыл җәйләре яме



Авыл җөе, шәһәрнекеннән аермалы буларак, үзенчәлекле бер яме, төме белән һәрчак үзенә дәшеп тора. Быел да ул көтүчелек «һөнәре»н үзләштерү, кызу печән өсте һәм ямьле җиләк вакытлары белән хәтердә калачак.

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

### Көтүче көндәлегеннән...

Быелгы җәй минем өчен сыер көтүе көтүдән башланып китте. Башка елларда авылыбызда малларны аерым кешеләр билгеле бер күләмдәге түләү хакына көткән булса, быел көтү – «чираттан». Хуҗалыкта көтүгә чыга торган ничә малың бар, шулкадәр көн «көтүче» булырга туры килә. Башта авыл халкы байтак вакыт былтыргы көтүчеләрнең быел да хезмәт куячагына өметләнде. Әмма, күрәсең, моның алай булмаячагын аңлап, "чират" белән килешергә мәҗбүр булды. Өстәвенә акчасы да янга кала.

Ничек кенә гаҗәп тоелмасын, авыл баласы булуыма карамастан, моңа кадәр әле бер тапкыр да көтүче булу бәхете татымады. Беренче тапкыр булгач, үзем дә кызыксынып киттем. Башкалар чыбыркы әзерләгәндә, үземә алдан ук талчыбык хәзерләп куйдым – сыерлары тыңлаусыз булса, кирәге чыгар, янәсе. Ә чыбыркы тоту кыз кешегә килешми, җитмәсә, аны тота да, шартлата да белмим. Иртәгесен торып, әзер сумкаларны җилкәгә асып, көтү көтәргә чыгып киттем. Көне артык салкын да, эссе дә түгел – әмма җиле каты. Ләкин зыян юк, иң мөһиме – өстән явып тормый. Беребез сыерларны югары оч, икенчебез – тау асты, Олы урамнан, өченчебез арт урамнан җыярга тиеш. Түбән очта сыерларның барысын бергә кушып көтүлеккә алып төшү – төп бурыч. Маллар инде болынга беренче көн генә чыкмый, шуңа ияләшеп үк беткәннәр. Артык куып интегергә дә туры килмәде. Сыерларның акыллылыгына исем китте. Болында да артык тәртипсезләнмәделәр. Шулай да арада «качкыннар»ы бар икән. Кайтырга берничә сәгать кала, авыл ягына таба элдертергә торалар. Әле башка сыерларны да үз артыннан ияртмәкчеләр. Ә кайтыр вакытлары җиткәч, малларны инде туктатам димә. Барысы бергә дәррәү килеп авылга кайттылар да киттеләр.

Шулай итеп мин дә быел көтү чиратының рәхәтен күрдем. Кызык икән ул. Тик, өйгә кайткач, бер генә сыерыбыз булуга сөенеп куйдым әле. Беренче көн булганга гына кызык , көн дә көтүче булуның авыр да, җаваплы да эш икәнлеген аңлыйм бит.



### Печән өсте – кызу чак

Быелгы печән өсте кызу булды. Яшел үлән мулдан үскән – үзе озын, үзе куе. Узган елгы кебек сирәк түгел инде. Чап та җый гына. Башка елларда кибеп өлгергән печән өстенә яңгыр койгалап китеп, аны кабаттан җилләтергә туры килсә, быел алай азапланмадык. Әти яшел үләнне көнләп чаба барды. Бер-ике көннән печәнне әйләндереп, җыеп, төяп алып кайтып сайгакка тутырдык. Әле июльнең башы гына – ә инде болын тулы халык. Умарта күчедәй гөжләп, бергәләшеп тыраша-тыраша яшел азык әзерлиләр. Ике атна вакыт эчендә күпме печән чабылды да никадәрле кибән куелды. Сайгаклар хуш исле кипкән печән белән тулы. Инде тыныч күңел белән кышны да каршыларга була.



### Җиләкле җәй галәмәте

«Бирсә бирә икән Ходай мул уңышны!» Безнең якларда быел җиләккә барган һәр кеше әнә шундый гаҗәпләнү катыш шатлык белән әйләнеп кайта. Җәй башында яуган яңгыр да, аеруча каты кыздырган кояш та җиләккә яхшы тәэсир иткән, күрәсең. Аның кадәрле җимешне безнең авылдагыларның инде күптәннән күргәннәре булмаган. Җиләкнең өлгергәнлеге генә түгел, ә эрелеге һәм күплеге чын мәгънәсендә шаккатыра.

Безнең авыл халкының күпчелеге җиләккә күрше Малмыжка авылы янындагы елгалыкка, таулыкка йөри. Үзебез дә инде 4 тапкыр бардык. Шунысы гаҗәп һәм кызык: дүрт барганында да нәкъ шул урыннан җыеп зур-зур чиләкләребезне тутырып кайтып киттек. Берничә көн аралаш барганга, күрәсең, җир җиләге һаман саен җыела һәм яңадан өлгерә тора. Әле, үч иткәндәй, чиләк тулып, кайтыр вакыт җиткәч кенә шундый эре җимеш белән тулы урынга юлыгасың, онытылып кабат җыярга керешәсең. Әмма куярга урын юклыкны аңлап, үзеңә иртәгә дә килергә сүз бирә-бирә кайтып китәсең.

Җиләк сезоны башланганнан бирле, инде дистәдән артык мәртәбә баручылар да бар икән. Булырлык та шул. Чөнки бер утыруда ун литрлы чиләкне тутыру быел әллә ни кыен булмады. Урыны-урыны белән хәтта бакча җиләге кадәр зурлыктагылары да очрап куя, исеңакылың китәр. Табигать, әйтерсең, былтыргы коры җәй вакытында бөресендә үк кибеп беткән җиләкне кире кайтара.

Үзем җиләк җыярга әллә ни оста түгел түгелен. Мәрхүмә әбиемә охшамаганмын, күрәсең. Фатыйма әби үз вакытында иң җитез «җиләкче»ләрнең берсе булган. Ләкин быелгы мул уңыш аркасында хәтта мин дә чиләгемне тиз арада тутырырга өйрәндем. Әле соңгысында җимешне чүбеннән чистартып ук җыйдым. (Минем өчен бу, әлбәттә, бик зур прогресс булды инде). Шул рәвешле кышка җир җиләге кайнатмасы, джемы, компоты җитәрлек әзерләнде быел.

● Студент колагына

# Яңа уку елы... яңа тормыш!

**Илмир ВӘЛИЕВ,** хәбәрче

Универсиада тәмамлангач, Казаныбыз бераз гына булса да кунаклар кабул итүдән туктап торды. Ләкин сентябрьгә аяк баскач, мәркәзебез кабат үзенең ишекләрен киң итеп ачты. Бу юлы чит ил кунакларына түгел, ә меңләгән студентлар армиясенә.

Җиһанда – көз һәм старт алган яңа уку елы. Җәйнең матур көннәре алтын көзгә буйсына башлады. Һава торышы үзгәреп торган кебек, кешенең дә яшәеше, көн тәртибе, тормышы үзгәрә. Үземнән чыгып әйтәм, беренче курс студентларына бу халәт аеруча таныш. Моңа кадәр алар үз өйләрендә, ата-ана карамагында иделәр. Хәзер алар, аналары очырган кошлар кебек, үз көнен үзләре күрә башлый. Әлбәттә, баштагы мәлне беренче курс студентларына яңа көн тәртибенә күнегергә, уку йортының корпусларында һәм аудиторияләрендә ориентлашырга бераз авыррак булыр. Шулай да вакыт үзенекен итәр: сизми дә калырсыз – барысына да күнегерсез. Эх, тиз уза да бу вакыт дигәннәре. Әле кайчан гына имтиханнарны тапшырып, каникулга чыккан идек. Күңелле һәм төрле вакыйгаларга бай студент тормышы тагын башланып китте. Мин дә икенче курска күчтем. Яңа уку елына үзеңне дөрес итеп ничек әзерләргә соң?

Яңа уку елы кайбер студентларда негатив тәэсирләр уята. Ник дигәндә, җәйге ялллардан соң, уку процессына кереп китү бик кыен була. Психологлар фикеренчә, август аенда ук үз-үзеңне укуга әзерли башларга кирәк. Август аеның соңгы ике атнасында яисә уку елы башында иртәрәк тора башларга, конспектларны язып өлгерер өчен, бармакларга күнегүләр ясарга һәм нинди дә булса вактөяк эшләр башкарыга тәкъдим ителә.

Тәүге тапкыр студент булучыларга үзләренең башларын тискәре уйлар белән тутырырга ярамый. «Мин укый алмаячакмын, миннән булмаячак», – дигән уйлар, гомумән, булырга тиеш түгел. Укуның беренче көненнән үк, үзеңне матур уй-фикерләр белән баетырга, һәрнәрсәгә позитив караш уятырга кирәк.

Яңа уку елы – яңа дуслар табу өчен менә дигән мөмкинлек. Дуслар кеше тормышында алыштыргысыз маяк булып тора. Дуслар янда булса, уку да тиз һәм бик күңелле уза.

Тагын шуны әйтәсе килә: Казан – студентлар өчен бик күп мөмкинлекләр мәйданы. Рәхәтләнеп концерт-театрларга, музей-күргәзмәләргә йөрергә, шәһәребезнең истәлекле, тарихи урыннары белән танышырга була. Алар бездә бик күп! Җаның ни тели, шуның белән мавыгып яисә башка, синең өчен яңа булган өлкәдә «җенләнеп» алырга була. Безнең белем сараенда мөмкинлекләр җитәрлек. Укы, җырла, бие, спорт белән шөгыльлән. Бары тик вакытыңны дөрес бүләргә өйрән!

Бер дә борчылмагыз, безнең уку йортында белем алу бәхете берничә көн эчендә күңелегезгә бик күп шатлыклы эмоцияләр, онытылмас мизгелләр салыр. Барысы да үзебездән тора. Теләргә һәм бирешмәскә генә кирәк!

Галәм кояшы белән якты, ә кеше белеме белән күркәм, белеме белән көчле. Әмма фәннең зәңгәр офыклары иксез-чиксез. Тирәнлек – диңгездә, зирәклек – гыйлемдә, дигәндәй, белем дәрьягыз тагын да тирәнәеп, тагын да зуррак уңышларга ирешерсез дип өмет итәбез.

Изге эшләр башлаган юлыгызда иминлек телибез. Юлларыгыз сикәлтәле булса да, авырлыкларны җиңел җиңеп, ил өстендә балкырдай ачышлар ясап, олы уңышларга ирешүегезне телибез.

● Кайда? Ничек? Кайчан?

## XV гасыр бәйрәме

Ни өчен уку нәкъ менә 1 сентябрьдән башлана соң? Кызык сорау...

Бу традиция безгә XV гасырдан, **Византиядән** үк килгән. Византия дин белгечеләре Аллаһы Тәгалә дөньяны нәкъ менә 1 сентябрь көнне яраткан дип санаганнар. Ул вакытка инде кыр эшләре дә тәмамланган һәм, җәй беткәч, авыл балаларын шәһәргә укырга җибәрергә дә мөмкинлекләр күбрәк булган.

1 сентябрь рәсми рәвештә бәйрәм статусын 1984 елда **СССРның Югары Советы** тарафыннан ала. **Россия** белән беррәттән **Чехия**, **Украина**, **Белорусия** һәм **Балтыйк** буе илләрендә 1 сентябрь – яңа уку елы булып санала.

Ә менә **Германиядә** уку елының төгәл графигы юк: анда уку йортлары август-сентябрь дәвамында эшли башлый.

**Испаниядә** дә билгеле бер дата юк. Анда бу процесс уңышның кайчан җыелып бетүенә бәйле рәвештә башкарыла. Шулай да, ул 1 октябрьгә кадәр гамәлгә ашырылырга тиеш.

**Дания** балалары август уртасыннан укый башласалар, **Англия**, **Канада** һәм **АКШ**та укучылар мәктәп бусагасын сентябрьнең икенче сишәмбесендә атлап керә. **Японияле**ләр исә уку елы башлануны бик ук кызык һәм күңелле дип исәплиләр, шуңа күрә алар 1 апрель көнне укый башлыйлар.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 500
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.